БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
20 ноябрь 2021 ел

**КАРАР**
№ 95

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроленең нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын бәяләү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроленең нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын бәяләү тәртибен әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Муниципаль урман контроленең төп күрсәткечләрен һәм аның максатчан зурлыкларын, муниципаль урман контроле өчен индикатив күрсәткечләрне әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы Советының
2021 елның 20 декабренең
95 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроленең нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын бәяләү
Тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроленең нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын бәяләү тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 маендагы 934-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә эшләнде.

2. Тәртип контроль эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын бәяләү һәм муниципаль контроль органы эшенең нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы күрсәткечләренә ирешүне контрольдә тоту кагыйдәләрен билгели.

3. Бәяләү системасы түбәндәге төшенчәләрне үз эченә ала:

- "муниципаль контроль нәтиҗәлелеге" - муниципаль контрольнең тиешле өлкәдә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне минимальләштерүдә чагылдырыла торган иҗтимагый әһәмиятле нәтиҗәләренә ирешү дәрәҗәсе;

- "муниципаль контроль файдалылыгы" - закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү куркынычын, шулай ук гражданнар һәм оешмалар эшчәнлегенә тыкшыну дәрәҗәсен бетерү дәрәҗәсе.

4. Контроль эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы күрсәткечләре төп ("А" төркеме) һәм индикатив ("В" төркеме) күрсәткечләрдән тора.

5. "А" төркеме күрсәткечләре, аларга ирешүне муниципаль контроль органы тәэмин итәргә тиеш булган максатчан күрсәткечләрне билгели торган иҗтимагый әһәмиятле контроль эшчәнлеге нәтиҗәләренә ирешү дәрәҗәсен чагылдыручы муниципаль контроль нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре булып тора.

6. "В" төркеме күрсәткечләре контроль эшчәнлеген сан ягыннан характерлый торган һәм муниципаль контроль органы эшен анализлау, мониторинг ясау өчен кулланыла торган индикатив күрсәткечләр булып тора.

7. "В" төркеме күрсәткечләре түбәндәге төркемчәләргә бүленә:

- "В.1." - үткәрелгән чаралар параметрларын характерлый торган индикатив күрсәткечләр;

- В. 2."- эшкә җәлеп ителгән хезмәт ресурслары күләмен характерлый торган индикатив күрсәткечләр.

8. Күрсәткечләрне билгеләү өчен хисап чоры булып календарь ел тора.

9. Муниципаль контроль органы ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, әлеге карарның 2 нче кушымтасында расланган күрсәткечләрнең фактлагы (ирешелгән) күрсәткечләрен исәпләүне һәм бәяләүне гамәлгә ашыра.

10. Күрсәткечләрнең фактлагы (ирешелгән) күрсәткечләрен бәяләү күрсәткечләрнең максатчан (индикатив) күрсәткечләре белән чагыштыру юлы белән башкарыла.

11. Фактлагы (ирешелгән) күрсәткечләрне бәяләү нәтиҗәләре 1 дән 5 баллга кадәр 5 баллы шкала буенча билгеләнә, күрсәткечләрнең максатчан зурлыклары буенча бирелә:

5 балл - әгәр фактлагы күрсәткеч максатчан норматив күрсәткечкә тигез булса;

4 балл - әгәр фактлагы күрсәткечнең максатчан күрсәткечтән тайпылышы 10% тан кимрәк булса;

3 балл - әгәр фактлагы күрсәткечнең максатчан күрсәткечтән тайпылышы 10% тан артык, әмма 30% ка җитмәгән булса;

2 балл - әгәр фактлагы күрсәткечнең максатчан күрсәткечтән тайпылышы 30% тан артык, әмма 40% ка җитмәгән булса;

1 балл - әгәр фактлагы күрсәткечнең максатчан күрсәткечтән тайпылышы 40% тан артык булса;

Татарстан Респуликасы
Балтач муниципаль районы Советының
2021 елның 20 декабренең
95 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль урман контроленең төп күрсәткечләре һәм аның максатчан зурлыклары, муниципаль урман контроле өчен индикатив күрсәткечләр

| Күрсәткеч номеры (индексы) | Күрсәткечләр исеме | Исәплəү формуласы | Зурлыкның аңлатмалары | Күрсәткечләрнең максатчан зурлыклары | Күрсәткечнең зурлыгын билгеләү өчен мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле (алга таба - муниципаль урман контроле) | | | | | |
| | Төп күрсәткечләр | | | | |
| А | Муниципаль урман контроленең әһәмиятле нәтиҗәләренә ирешү дәрәҗәсен чагылдыра торган нәтиҗәлелек күрсәткечләре | | | | |
| А. 1. | Муниципаль милектә булган урман кишәрлекләренә карата урман законнары таләпләрен бозуның ачыкланган саны | | | Үлчәү берәмлеге | |
| А. 2. | Муниципаль милектә булган урман кишәрлекләре-нә карата урман законнары таләпләрен | Кн х 100% / Пф | Кн- ачыкланган бозулар саны (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бозуның ачыклангап санының тикшерүләрнең гомуми санына карата өлеше | | | | |
| Индикатив күрсәткечләр | | | | | |
| В | Муниципаль урман контроленең төрле аспектларын характерлый торган индикатив күрсәткечләр | | | | |
| В. 1. | Үткәрелгән чаралар параметрларын характерлый торган индикатив күрсәткечләр | | | | |
| В. 1.1. | План (рейд) биремнәре (караулары) үтәлеше | Врз = (РЗф / РЗп) х 100 | Врз - план (рейд) биремнәренең (карауларның) үтәлеше % РЗф- үткәрелгән рейд биремнәре (караулары) саны (бер.) РЗп- планлаштырылган рейд биремнәре (караулары) саны (бер.) | 100% | Расланган план (рейд) биремнәре (караулары) |
| В. 1.2. | Планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре | Ввн = (Рф / Рп) х 100 | Ввн- планнан тыш тикшерү үтәлеше Рф- планнан тыш үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) Рп- планнан тыш тикшерүләр | 100% | Татарстан Республика-сы Балтач район башкарма комитетына килгән хатлар һәм шикаятьләр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | үткәрү өчен гаризалар саны (бер.) | | |
| В. 1. 3. | Нәтиҗәләренә шикаять бирелгән тикшерүләр өлеше | Ж х 100 / Пф | Ж- шикаятьләр саны (бер.)<br>Пф- үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 0% | |
| В. 1. 4. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган тикшерүләр өлеше | Пн х 100 / Пф | Пн - дөрес түгел дип табылган тикшерүләр саны (бер.)<br>Пф- үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 0% | |
| В. 1. 5. | Милекче булмау һ. б. сәбәпләр аркасында үткәрелмәгән планнан тыш тикшерүләр өлеше | По х 100 / Пф | По- тикшерелүче зат булмау сәбәпле үткәрелмәгән тикшерүләр (бер.)<br>Пф- үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 10% | |
| В. 1. 6. | Планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында прокуратурага килештерүгә җибәрелгән, аларны килештерүдән баш тартылган гаризаларның | Кзо х 100 / Кпз | Кзо - аларны килештерүдән баш тарткан гаризалар саны (бер.)<br>Кпз- килештерүгә бирелгән гаризалар саны | 10% | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | әлеше | | | | |
| В. 1. 7. | Нәтиҗәләрe буенча материаллар карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр өлеше | Кнм х 100 / Квн | Кнм- вәкаләтле органнарга җибәрелгән материаллар саны (бер.) Квн- ачыкланган бозулар саны (бер.) | 100% | |
| В. 1. 8. | Вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр һәм рейд биремнәре материаллары буенча салынган административ штрафларның гомуми суммасы | | | Сумма мең сум. | |
| В. 1. 9 | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | | | Данә | |
| В. 2. | Файдаланылган хезмәт ресурслары күләмен характерлаучы индикатив күрсәткечләр | | | | |
| В. 2.1. | Штат берәмлекләре саны | | | Кеше | |
| В. 2.2. | Муниципаль контроль органы хезмәткәрләренә контроль чаралар йөкләнеше | Км / Кр = Нк | Км- контроль чаралар саны (бер.) Кр- муниципаль контроль органы хезмәткәр-ләре саны | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | (бер.)<br>Нк - 1 хезмәткәргә йөкләнеш (бер.) | | |